**Аннотация**
**к рабочей программе воспитателя по обучению детей родному языку**
**Курамшиной М.Н.**

Программа 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларның татарча аралашырга өйрәтү эшчәнлекләренең эчтәлеген чагылдыра. Программа мәктәпкәчә яшьтәге баланың үсеш закончалыкларына, шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы фундаменталь тикшеренүләргә, тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына (Л. С. Выготский, П. Я. Гальперин, В. В. Давыдов, Е. А. Пассов) чагылыш тапкан фәнни тикшеренүләргә, гамәли эшкәртмәләр һәм методик киңәшләргә, мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив хокукый актлар, нигезләмәләренә көйләнгән.

Туган телне саклау һәм үстерү – көнүзәк мәсьәлә. Федераль дәүләт белем бирү стандартларында да дәүләт телләренә зур игътибар бирелә. Шәһәр шартларында үскән балаларның күбесе, гаиләдә ана теленә мөнәсәбәт дөрес булмау сәбәпле (мәсәлән,татар гаиләләрендә русча сөйләшү), үз туган телен икенче тел буларак өйрәнә башларга мәҗбүр. Милли үзаңның нигезе гаиләдә, туган телдә даими сөйләшү аркасында гына салынуын ата-аналар аңлап бетермиләр. Югарыда китерелгән фикерләргә нигезләнеп, без дә туган телен яхшы белмәгән бала, һичшиксез, балалар бакчаларында ук үз телен өйрәнә башларга яки белгән кадәрлесен камилләштерергә дигән фикерне алга сөрәбез. Безгә, тәрбиячеләргә, хәзерге көндә бу юнәлештә эшләү зарур. Шуңа күрә без, бу методик кулланманы тәрбия эше рус телендә алып барыла торган балалар бакчаларында балаларны ана телендә сөйләшергә өйрәтү өчен тәкъдим итәбез.

Методик кулланмада рус төркемнәрендә тәрбияләнүче, гаиләләрендә җитәрлек дәрәҗәдә татарча аралашмаган, 2-7 яшьлек татар балаларының сөйләмен үстерү һәм аларны ана теленә өйрәтү комплекслы-тематик, календарь-тематик планнар һәм диагностика сораулары бирелгән.

“Туган телдә сөйләшәбез” методик кулланмасының 2 нче варианты Ф.В.Хәзрәтова, З.М.Зарипова җитәкчелегендәге иҗади төркем чыгарган “Туган телдә сөйләшәбез” методик әсбаплары, К.В.Закированың “Балачак аланы” хрестоматиясе, З.М.Зарипованың “Татарча сөйләшәбез” методик ярдәмлекләре,”Тамчы”театр түгәрәге һәм сәләтле балалар белән эшләү өчен “Туган телдә сөйләшик”авторлык программалары нигезендә төзелде.

Бу методик кулланмада Федераль дәүләт белем бирү стандартларында күрсәтелгән биш белем бирү өлкәсе карала: социаль-аралашу үсеше, танып-белү үсеше, сөйләм үсеше, физик үсеш, нәфис-нәфасәти үсеш.

*Социаль-аралашу үсеше* юнәлеше балаларда туган телгә хөрмәт тәрбияләү, матур әдәбият әсәрләре белән кызыксыну уяту, авазларны дөрес әйтү, диалогик сөйләм күнекмәләрен камилләштерү бурычларын үз эченә ала. Бу өлкәдәге эшчәнлек әңгәмә, үстерелешле диалог, ситуатив күнегүләр, сәхнәләштерү кебек эш формаларын күздә тота.

*Танып-белү үсеше* юнәлеше табигать, аның үзенчәлекләре, экологик бәйләнешләр белән таныштыру, балаларның ел фасыллары турындагы белемнәрен тирәнәйтү, системалаштыру, туган як, өлкәннәр хезмәте турында белемнәрен тирәнәйтүне максат итеп куя.

*Сөйләм үсеше* сүзлек эше, сөйләмнең грамматик төзелеше өстендә эш, ишетеп кабул итү, аваз культурасы тәрбияләү, балаларны матур әдәбият һәм халык авыз иҗаты белән таныштыру, дөрес структуралы җөмләләр, рәсемнәр буенча гади хикәяләр төзү кебек эш формаларын күздә тота.

*Физик үсеш* юнәлешендә балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килә торган хәрәкәтле уеннар, ял минутлары оештырыла.

*Нәфис-нәфасәти үсешенә* җырлы-биюле уеннар уйнау,җырлар тыңлау һәм җырлау, матур әдәбият әсәрләре уку, шигырьләр өйрәнү керә.

Нәниләрнең сөйләмне үзләштерүләрендә авазларны һәм сүзләрне дөрес өйрәнүләрендә, сүз запаслары артуда да уеннарның әһәмияте әйтеп бетергесез. Бигрәк тә сүзле, җырлы-биюле уеннар вакытында балаларның теле ачыла. Алар үз туган теленең аһәңлелеген, матурлыгын тоя белергә өйрәнә, фантазияләре үсә. Уеннар сайлаганда, без аның тәрбияви әһәмиятен, максатын һәм бурычларын күз алдында тоттык. Ул төрле эшчәнлек формасында – ситуация, ял итү, аралашу, мәгълүмати-аралашу технологияләре куллану, бәйрәм һ.б. кысаларда алынды.

Кулланмада сүзле, хәрәкәтле уеннар аралаштырылып, баланың яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып бирелде.

Методик кулланма һәр үсмер төркемдә атнага өч эшчәнлек исәбеннән төзелде.

4-7 яшьлек балалар өчен өченче эшчәнлекләр бөтен төркем белән уздырыла торган итеп кертелде.

Эшчәнлекләрдә балаларда аралашуга теләк уяту,бәйләнешле сөйләм үстерү, матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру бурычлары куелды. Эшчәнлек конспектларында тәрбияче өчен аңлатмалар, әдәбият, җиһазлар, лексик доза, эш төрләре күрсәтелде.

Методик кулланмада балалар эшчәнлеген оештыру комплекслы-тематик планлаштыру нигезендә бара. План ел дәверендә төрле темалар үзләштерүне күздә тота. Бу темаларның күбесе һәр төркемдә диярлек кабатлана. Шуңа күрә, гадидән катлаулыга бару - кулланмада төп методик принципларның берсе.Эшчәнлек үрнәкләрендә без боларны мөмкин кадәр эзлекле сакларга тырыштык.

Беренче кечкенәләр төркемендә тәрбияләнүче татар балалары өчен укыту материалы ел дәвамында 15 проектка бүленеп өйрәнелә: “Исәнме,балалар бакчасы”,“ Уенчыклар”, “Күз” ,

“ Минем йортым,минем шәһәрем” ,“Гаилә” ,“Кыш” ,“Яңа ел бәйрәме” , “

“Ватанны саклаучылар көне” , ” 8нче март” , “Әкияттә кунакта” , “Бәйрәмнәр” , “Яз” , “Җәй” , “Безнең авылда”, “Кыргый хайваннар”.Ел буена барлыгы 105 сәгатькә җыела. Һәрбер проект темаларга бүленгән. Балаларның сөйләшү, аралашу һәм яшь үзенчәлекләрен истә тотып лексик доза (актив, пассив сүзләр) бик аз күләмдә кулланылды. Төрле уеннар, рәсемнәр буенча сорауларга җавап бирү, 2-3 яшьлек балалар аңларлык дәрәҗәдә генә. Беренче яртыеллыкта пассив сүзләр күбрәк файдаланылса, икенче яртыеллыкта инде актив сүзләр күбрәк кулланылышка кертелде.

Икенче кече яшьтәгеләр төркемендә темаларны яктыртканда, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, аларга якын, үзенең әйләнә-тирәсе белән бәйле әйберләргә өстенлек бирдек.

Балаларның сүз байлыгы арту нәтиҗәсендә, аралашу дәрәҗәсе киңәя. Шуңа күрә, балаларның бәйләнешле сөйләмен үстерүгә зур игътибар бирелә. Методик кулланмада лексик доза актив һәм пассив (курсив белән бирелә) сүзләргә бүленеп күрсәтелә.

Эшчәнлек планнарында сорауны белдерүче кисәкчәләрне (мы-ме), аерым сүзләрне истә калдыру максатыннан чыгып, җәяләр эчендә язылды:-син кыз(мы)?, -туп зур(мы)?

Уртанчылар төркемендә алты проект өстәлде: “Ашамлыклар”, “Татар халык ашлары”, “Халык җәүһәрләре”, “Киемнәр”, “Күчмә кошлар”,”Сабантуй”.

Уртанчылар төркеме балаларын –мы, -ме сорау кисәкчәләре белән таныштыру, шулар ярдәмендә өстәмә сорау бирү һәм дөрес җавап кайтару максаты куелды.

5-6 яшьлек балалар эшчәнлеген оештырганда, түбәндәге проектлар өстәлде: “Абдулла Алиш”, “Мин яратам сине, Татарстан!”, “Кунак булсаң – тыйнак бул”, “Муса Җәлил безнең күңелләрдә”, “Чисталыкта – матурлык”, “Җиңү алып килде безгә май”, “Хәрәкәттә – бәрәкәт”. Бу темалар әдәп-әхлак, патриотик хисләр тәрбияли. Бу яшьтә балаларның кечкенә хикәяләрне мөстәкыйль төзи белүе монологик сөйләмне камилләштерүдә мөһим күрсәткеч булып тора.

Мәктәпкә әзерлек төркеме балаларына “Икмәк – яшәү терәге”, “Башкалам – Казан”, “Кышлаучы кошлар”, “Бөтендөнья телләр көне”, “Мәктәп”, “Урман” проектлары кертелде. Бу төркемнәрдәге эшчәнлек әңгәмә, үстерелешле диалог, сәхнәләштерү, рәсемнәр карау, алар буенча хикәя төзү, тасвирлау, үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү кебек эш формаларын күздә тота. Эшчәнлекләр матур әдәбият әсәрләрен уку, ятлау, халык авыз иҗатын өйрәнү кебек эш формалары кулланып оештырыла.

Федераль дәүләт мәктәпкәчә белем бирү стандарты таләпләре буенча, эшчәнлекләр уен рәвешендә оештырыла. Балалар төрле ситуацияләр чишәләр, уеннар уйныйлар, сәяхәткә баралар, күзәтәләр һәм шул рәвешле телне тоемлау сәләте булдыралар, ана телендә дөрес итеп сөйләшергә өйрәнәләр. Эшчәнлек ахырында балаларга проблемалы сораулар куела һәм алган белемнәрен ныгыту өчен юнәлеш бирелә.

“Туган телдә сөйләшәбез” методик кулланмасы – балаларыбызга халкыбызның тел хәзинәсен тирәнтен аңларга, кеше өчен газиз булган туган җиргә, туган телебезгә хөрмәт, әти-әниләргә, өлкәннәргә карата итәгатьлелек тәрбияләргә, үзләрендә хезмәт сөю, тыйнаклык, шәфкатьлелек кебек күркәм сыйфатлар булдырырга ярдәм итәр дип ышанасы килә .

**Укыту методик комплектының эчтәлеге.**

***Уртанчылар төркеме “Минем өем” проекты***

***(4-5яшьлек балалар өчен)***

Проект түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) тематик план;
2) эшчәнлек конспектлары;
3) балалар һәм әти-әниләр өчен эш дәфтәрләре -17 бирем;
4) аудиоязмалар- 64 кисәк (трэк)
5) анимацион күренешләр-– 11 данә
6) күрсәтмә, таратма материаллар;
7) диагностик материаллар.

Актив сүзләр+ сөйләм үрнәге – 62 (269).

**Актив сүзләр:** әти, әни, кыз, малай, мин, исәнмесез, сау булыгыз, исәнме, эт, песи, әйе, юк, сау бул, әби, бабай, әйбәт, ипи, алма, сөт, чәй, рәхмәт, мә, тәмле, кил монда, утыр, бир, аша, эч, туп, зур, кечкенә, матур, курчак, куян, аю, хәлләр ничек, уйна, пычрак, чиста, ю, бер, ике, өч, дүрт, биш (49 сүз).

**Сөйләм үрнәге:** утырыгыз, бу кем?, кем юк?, син кем?, кем анда?, басыгыз, ал, ничә? нинди? (13 сүз).

**Проектның эчтәлеге түбәндәге темалардан тора:**

- Гаилә
- Ашамлыклар
- Уенчыклар
- Саннар (1-5)

Атна дәвамында 20 шәр минутлык 3 эшчәнлек оештырыла.

***Зурлар төркеме“Уйный – уйный үсәбез” проекты***

***(5-6 яшьлек балалар өчен)***

Проект түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) тематик план;
2) эшчәнлек конспектлары;
3) балалар һәм әти-әниләр өчен эш дәфтәрләре -19 бирем;
4) аудиоязмалар- 63 кисәк (трэк)
5) анимацион күренешләр-– 15 данә
6) күрсәтмә, таратма материаллар;
7) диагностик материаллар.

Актив сүзләр+ сөйләм үрнәге – 46 (406).

**Актив сүзләр:** кишер, нинди, баллы, ничә, суган, бәрәңге, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кыяр, кәбестә, кызыл, сары, яшел, кирәк, юа, нәрсә кирәк, аш, ботка, кашык, тәлинкә, чынаяк, зәңгәр, күлмәк, чалбар, ки, сал, йокла, бит, кул, өстәл, урындык, карават, яратам, бар (38сүз)

**Сөйләм үрнәге:** бу нәрсә?, хәерле көн, нәрсә бар? күп (7 сүз).

**Проектның эчтәлеге түбәндәге темалардан тора:**

- Яшелчәләр
- Ашамлыклар
- Савыт-саба
- Киемнәр
- Шәхси гигиена
- Өй җиһазлары
- Бәйрәм “Туган көн”
- Бәйрәм “Сабан туй”
- Уртанчылар төркемендәге темалар(гаилә, ашамлыклар, уенчыклар, саннар) ел дәвамында кабатлана.

Атнага 25 шәр минутлык 3 эшчәнлек оештырыла.

***Мәктәпкә әзерлек төркеме "Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар" проекты (6-7 яшьлек балалар өчен)***

Проект түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) тематик план;
2) эшчәнлек конспектлары;
3) балалар һәм әти-әниләр өчен эш дәфтәрләре -20 бирем;
4) аудиоязмалар- 71 кисәк (трэк)
5) анимацион күренешләр-– 19 данә
6) күрсәтмә, таратма материаллар;
7) диагностик материаллар.

Актив сүзләр+ сөйләм үрнәге – 60(483 сүз булган).

**Актив сүзләр:** син кем, хәерле көн, тычкан, бу кем? бу нәрсә? нишли?, йоклый, утыра, ашый, эчә, нишлисең?, ашыйм, эчәм, уйный, уйныйм, утырам, барам, кая барасың?, син нишлисең?,сикер, сикерәм, сикерә, йөгерә, төлке, йөгер, йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, җырла, җырлыйм, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр, нәрсә яратасың?(пассив сүз)

Проектның эчтәлеге уртанчылар, зурлар төркемендә өйрәнгән сүзләргә таянып аралашуга корылган. Атнага 30 ар минутлык 3 эшчәнлек оештырыла.